**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРБӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

19 нчы июнь 2020 ел № 111

**IV чакырылыш Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Шәрбән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына депутатлар сайлау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 06 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 ел, 07 май, №21-ЗРТ 105 нче статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Шәрбән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. IV чакырылыш Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Шәрбән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Авыл таңнары» газетасында аның кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлеге Советы рәисе Д.Ә.Шәрифуллин